**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Тлянче-Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

15 ноябрь, 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә, 2019 елның 14 ноябрендә, 2019 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2020 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче-Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юл ремонтлау.
- Сабантуй бэйрэмен уткәрү һәм бүләкләр алу

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы ***866*** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – ***469*** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы ***469*** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче-Тамак авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2020 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче-Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә

500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юл ремонтлау.

- Сабантуй бэйрэмен үткәрү һәм бүләкләр алу;» мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче-Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче-Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ш. Нәҗметдинов

ОГРН 1051649011783
р 05-11793/09
Совет ТЛЯНЧЕ-ТАМАКСКОГО сельского поселения
ИНН 1639031748